

Безнен сугышчыларга ярдәм итv - һәркемнен уртак омтылышы һәм изге бурычы.
Мордовия халкы - искәрмә (исключение) тvгел. Безнен егетләргә махсус хәрби операция зонасына даими рәвештә барлык кирәкле әйберләрне жибәрәләр, һәм һәр йокнен моһим олеше – маскировка челтәрләре vрәләр. Кадошкино районы Большие Поляны авылында аларны арымыйча vрәләр. Алар сугышчыларга кvпме челтәр китvе һәм битараф булмаган якташлар аларга ярдәм итәргә әзер булулары турында сойләделәр.
Большие Поляны клубы бинасында Адиля Зәкәрья кызы Альмяшева, Равилә Фәрит кызы Альмяшева, Венера Амин кызы Долотказина, Зухра Хосәен кызы Долотказина, Екатерина Федоровна Кильдеева, Надия Хусаин кызы Кильдеева, Равилә Амин кызы Курамшина, Надия Али кызы Капкаева блиндажларны һәм хәрби техниканы маскировкалау очен саклау челтәрләре vрәләр, гуманитар ярдәм жыялар. Тиздән 90-яшьлек юбилеен билгеләргә жыенган Анна Сергеевна Лошкарева, кызы Валентина Алексеевна Чепина һәм оныгы Анна Владимировна Уторова белән челтәрне ойләрендә тукыйлар. Рима Закир кызы белән Фәрит Халил улы Ляпиннар да ойдә сеткаларны vрәләр. Маскировка челтәрләре бәйләvчеләр ятьмәләрнен солдатларга ярдәм итәчәгенә ышана, чонки СВОда катнашучылар ойләренә исән-сау кайтсыннар дип, дога кылып эшләнгән.
Тагы алар ашамлыклар жыеп жибәрәләр. Челтәр тукучыларнын бу жаваплы һәм кирәкле эштә барысы да катнаша һәм аларга кушылып Мусякаева Роза Абубәкәр кызы, Наилә Әхмәт кызы Капкаева, Наилә Хафиз кызы белән Рафаэль Ибрагим улы Долотказиннар, Камиль Билял улы Капкаев, Нурия Хаким кызы Еналеева изге эшне башкаралар.
Рафаэль Ибрагим улы машинасында ярдәмгә жыелган әйберләрне илтеп тә куя.
Авыл хатын-кызларынын тавык чvпләп бетерә алмаслык кvп эштән бушаган вакытта безнен сугышчыларга ярдәм итәргә омтылалар. Сез дә vз олешегезне кертә аласыз һәм якташларыбызга - СВОда катнашучыларга ярдәм итә аласыз.
Бу катлаулы вакытта читтә калмаган һәркемгә тvбән баш иябез. Сезнен тырышлыгыгыз безнен уртак жинvебезне якынайта!